РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» 07 2019 г. №471

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 11 февралендәге «Ютазы муниципаль районында эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне башкаруның административ регламентын раслау турында " 120 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 апрелендә 275 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләр башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 16 мартындагы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча № 237 санлы тәртибе, ТР Ютазы районы прокуратурасының 2019 елның 25 июнендәге «Ачыкланган коррупцион факторны бетерү максатында норматив хокукый актны үзгәртү турында» 02-08-04 санлы таләпләрен карап тикшергәннән соң, карар бирәм:

1. Ютазы муниципаль районында Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне башкаруның административ

регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба - Административ регламент):

Административ регламентның 24 пунктындагы 4 абзацны түбәндәге төрдә кабул итәргә:

" Камераль тикшерүләр үткәргәндә, Финанс-бюджет палатасы рәисе боерыгы буенча тикшерү (обследование) гамәлгә ашырыла".

Административ регламентның 45 пунктындагы 3 абзацны түбәндәге төрдә кабул итәргә:

«Әлеге пунктта күрсәтелгән запросны җибәргән очракта, вазыйфаи зат яисә вәкаләтле зат, шикаятьне карау срогын өч эш көненнән дә артмаган вакытка озайта, аны карау срогын озайту турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә.

2. Әлеге Карар, аны рәсми бастырып чыгарган көннән соң (халыкка игълан иткәннән соң) үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы

муниципаль районы Башкарма

комитеты җитәкчесе С.П. Самонина